**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**

422750, село Большая Атня,
улица Ш.Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Ш.Мәрҗани урамы, 6 нчы йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» июнь 2025 ел. № 26

**Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлегендә урнашкан 16:10:010114:71 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен төп җирдән шартлы рөхсәт ителгәнгә үзгәртү буенча ачык тыңаулар билгеләнеше.**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2023 №131-ФЗ Федераль Законына, Әтнә муниципаль районының Әтнә район Советының 15.09.2023 № 195 карары белән расланган Олы Әтнә авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә таянып, Әтнә муниципаль районы Уставы нигезендә, Әтнә муниципаль районында гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә белән карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Әтнә муниципаль районы, Олы Әтнә авыл җирлеге, Олы Әтнә авылы, К.Маркс урамы, 22 нче йорт адресы буенча урнашкан 16:10:010114:71, кадастр номерлы җир индивидуаль торак төзелеше зонасында (Ж1) кишәрлегеннән файдалануның «Кибетләр» шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проектын карау буенча ачык тыңаулар үткәрергә.

2. Билгеләргә:

2.1. Ачык тыңаулар оештыручы Әтнә муниципаль районының авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектларын әзерләү һәм аларга үзгәрешләр кертү комиссиясен;

2.2. Үткәрү вакыты һәм урыны:

17.06.2025 ел. 10:00 – Олы Әтнә ав., К. Маркс ур., 22 з/у. - Галиева Г.З. җир кишәрлеге янында

2.3. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелергә мөмкин Адрес: Олы Әтнә авылы, Ш.Мәржэни

урамы, 6 йорт, Әтнә район башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге, электрон почта 21013okc@mail.ru, элемтә өчен телефон: 88436921013, эш вакыты: дүшәмбе-җомга 8: 00 дән 17:00 гә кадәр, 16.06.2025 г.кадәр.

3. Әтнә муниципаль районының авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләр проектларын әзерләү һәм аларга үзгәрешләр кертү комиссиясенә:

3.1. Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен гамәлдәге законнарга туры китереп һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда үзгәртү буенча ачык тыңаулар уздыруны оештырырга.

3.2. Ачык тыңаулар уздыру нәтиҗәләре турында беркетмә һәм бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

3.3. Рөхсәт ителгән файдалануның төрен үзгәртә торган җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган хокук ияләренә, җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренә һәм рөхсәт ителгән файдалануның төрен үзгәртә торган җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган капиталь төзелеш объектларының өлеше булган урыннарның хокук ияләренә хәбәр итәргә.

4. Әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проектын Әтнә муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга (atnya.tatarstan.ru)

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әтнә муниципаль районы
башлыгы вазыйфасын башкаручы Ф.М.Нуриев